Татарстан  Республикасы Мамадыш муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе
«Мамадыш шәһәре 5 нче «Бәләкәч» балалар бакчасы»




Мамадыш, 2026

**Эчтәлек:**

1. Аңлатма язуы
2. Актуальлек
3. Максат
4. Бурычлар
5. Катнашучыларның яше
6. Проектның тибы
7. Тормышка ашыру вакыты
8. Катнашучылар
9. Үткәрү урыны
10. Проектның планлаштырылган нәтиҗәләре
11. Календарь-тематик планлаштыру
12.“Мин атам - син әйт!” уены.
13. Сөйләм шакмагының ярдәмлеге
14. Йомгаклау
15. Әдәбият
16. Кушымта

## Аңлатма язуы

Бүгенге көндә туган телебезне саклау, өйрәнү һәм үстерү балалар бакчасында мәктәпкәчә белем бирү эшчәнлегендә мөһим урын алып тора. Татар теленең бүгенге халәте бик аяныч хәлдә. Тәрбиячеләрнең дәтөп бурычлары булып балаларны дөрес һәм чиста итеп туган телдә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, баланыңфикерләвен үстерү, сүзлек запасын баету. Әлеге максатны без балаларга һөнәри юнәлеш биргәндә дә куябыз. Баланың беренче адымнарыннан ук, ата-аналар аның киләчәге турында уйлана, үз баласының мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын игътибар белән күзәтә.

## Актуальлек

Татарстан Республикасында соңгы дистә елда туган телләрне саклау һәм үстерү юнәлешендә зур эшләр алып барыла. Бу юнәлештә туган тел укытучылары, методистлары, фән-мәгариф учреждениеләре генә түгел, журналистика оешмалары да зур көч куя. “Шаян ТВ” балалар телеканалы ачылуы, “Татмедиа-Junior” интернет платформасы, “Саф” балалар, “Белем” радиоларының ачылуы әти-әниләрдә һәм аларның балаларында татар телен өйрәнүгә кызыксындыру белән бергә ихтыяҗ да тудырды. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәләтләрен үстерү белән бергә сөйләм теле күнекмәсен ныгытырга, сәхнә телен өйрәнергә, телевизион һәм радио этикетын үзләштерергә мөмкинлекләр барлыкка килде. Ләкин бу проектларның барысы да татар дөньясының милли-мәдәни үзәге - башкалабыз Казанда тормышка ашырыла. Республика районнарында татарның бай мираслы аһәңле сөйләм телен яшь буынга тапшыруда төп көч белем бирү оешмаларына кайтып кала.

Казан мэриясе һәм Казан шәһәре башкарма комитеты Мәгариф идарәсе оештырган “Телне өйрәнүнең нәтиҗәле алымнары” семинарында чуваш теле белгече Александр Блинов телне заманча, яшьләрчә, матур итеп тәкъдим иткән очракта, ул үзенә җәлеп итә дигән фикерен яңгыратты [1]. Телне әти-әни, туганнар, дуслар белән аралашканда гына түгел, тормыш-көнкүрештә дә куллану зарур. Мамадыш шәһәрендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен дә татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ һәм кызыксыну тудыру максатыннан, “Бәләкәч” балалар бакчасында “Сөйлибез һәм күрсәтәбез” телевизион студиясен эшләү гамәлгә кертелде[1]. Биредә репортаж, интервью, иртәнге әкиятләр, интеллектуаль уеннар һ.б. тапшыруларны бакчага йөрүче балалар үзләре төшерә, ягъни бала алып баручы, диктор, интервьюер, тавыш яздыручы ролендә эшли [2].

Бакчада тәрбияләнүче балада журналистлык күнекмәләрен булдыру максатында шакмаклар ярдәмендә билгеле бер тема өстендә эшләү зарур. Яңа лексиканы өйрәтү, ныгыту, яңа сүзләр ярдәмендә сорау һәм хикәя җөмлә төзергә өйрәнү өчен шакмак ярдәмендә төрле методик ысул-алымнарны куллану уңай нәтиҗәләргә китерә. “Сөйләм шакмаклары” дип аталган методик “сандык” төрле теманы яктырткан рәсемле фигуралардан гыйбарәт. Шакмакның бер ягында урын алган рәсем бала хәтерендә яңа сүзне, сүзтезмәне, җөмләләрне отып алырга һәм җанлы сөйләмдә кулланырга ярдәм итә. Шакмакның һәр ягына урнаштырылган рәсемнәр тематик, логик һәм псхиологик яктан эзлекле рәвештә бер берсенә тоташып, үзара үрелеп бара һәм өйрәнелә торган теманың эчтәлеген тәшкил итә. Рәсемнәр - баланың яшь үзенчәлеген исәпкә алып сайлана, кызыклы заманча жанрда ясала, зур сюжет сызыгын үз эченә ала. Бу, билгеле, визуал балалар өчен аеруча уңай нәтиҗә бирә. Аудиаллар өчен (андыйлар мәктәпкәчә яшьтә бик сирәк очраса да) рәсем янына куаркодка яшерелгән аудиоязма бирелә. Шул ук вакытта кинестетик сабыйларның үзенчәлекләрен исәпкә алып, әлеге шакмакта күрсәтелгән рәсемнәрне студиядәге төрле уенчыклар, җиһазлар баетып тора. Бала шакмактагы рәсем ярдәмендә яңа

теманы ача, яңа сүзләр, гыйбарәләр өйрәнә, аудиоязма тыңлый һәм бүлмәдәге предметларны тотып, иснәп карау аша яңа белемнәрне үзләштерә һәм гамәлдә кулланырга тырыша.

**Максат:**

мәктәпкәчә яшьтәге баланың социаль-коммуникатив үсеше чарасы буларак шакмаклар ярдәмендә «Балалар журналистикасы» алымы белән таныштыру.

**Бурычлар:**

✓ педагогларны бер-берсе белән уртак тел табып эшли белүне, ярдәм итүне булдыру. Ана телебез белән горурлану хисе тәрбияләү өстендә эшләүне дәвам итү;

✓ бәйләнешле диалог сөйләмен үстерү;

✓ шакмаклар ярәмендә телетапшыру эшләргә өйрәтү. Сүзлек запасын арттыру (микрофон, камера, экран, журналист һ.б.);

✓ сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү;

✓ парлап эшләргә өйрәнү;

✓ туган телгә кызыксыну уяту.

**Катнашучыларның яше**: мәктәпкә әзерлек төркеме балалары.

**Уенның тибы:** иҗади, төркемчәләп, гаилә белән.

**Проектның тормышка ашыру вакыты**: 1 ел (1.01.2026-30.12.2026)

**Проектта катнашучылар:** тәрбияче, 6-7 яшьлек балалар, ата-аналар.

**Үткәрү урыны:** Мамадышның 5 нче санлы “Бәләкәч” балалар бакчасы һәм Мамадыш шәһәре.

**Үткәрү вакыты:** гыйнвар - декабрь.

**Эш режимы:** атнага бер тапкыр, шөгыльләрдән соң, кичке якта, дәвамлылыгы-25-30 минут, балаларның физиологик үзенчәлекләре СанПиН 2.4.1.3049-13белән каралган вакыт белән туры килә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

- ✓ бала эшчәнлекнең төп алымнарын үзләштерү, төрле эшчәнлек төрләрендә - уен, аралашу, зурлар белән иркен аралашу, үзен кеше, камера каршында иркен тоту;
- ✓ икетеллелек шартларында балаларның сөйләм теле камилләшү;
- ✓ бала дөньяга, төрле хезмәт төрләренә, башка кешеләргә һәм үзенә уңай мөнәсәбәт урнаштырырга сәләтле булуын күрсәтү;
- ✓ яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән актив хезмәттәшлек итү, уртак уеннарда катнашуы;
- ✓ гади хезмәт эшчәнлеген мөстәкыйль сайлау һәм оештыру тәҗрибәсе формалашу;
- ✓ эти-әнисенең һөнәре белән горурлану;
- ✓ татар теле белән кызыксына башлавы ;
- ✓ дөрес интонация белән сөйләшергә, аралашырга өйрәнүе.

**Календарь-тематик планлаштыру**

| № | Тема | Үткәрү вакыты | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Шакмаклар ярдәмендә барлык һөнәр ияләре белән танышу | Гыйнвар | Мәктәпкә әзерлек төркеме эти-әниләре |
| 2 | Хирург һәм балалар табибы белән әңгәмә кору | Февраль | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм әниләре |
| 3 | 1.«Серле шакмаклар» (рәсемнәр ярдәмендә) әңгәмә төзү<br>«Ярдәм ит әле» уены аша бер-берсенә ярдәм итергә өйрәтү.<br>Маллар табибеннән әңгәмә корырга өйрәтү | Март | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм эти-әниләре |
| 4 | Хәрәкәтле уеннар аша балада һөнәрләргә кызыксыну уяту.<br>Җәмгыятьтә булган төрле социаль катламнарга тигез мөнәсәбәт булдыру,<br>тирә якка игътибарлырак булу.<br>Пешекче һөнәрен үзләштерү. | Апрель | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм эти-әниләре |
| 5 | "Мин атам-си әйт" уены аша бизәндерүче һөнәрен яхшырак үзләштерү. | Май | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм эти-әниләре |
| 6 | Мамадыш шәһәре башлыгы белән шакмактагы рәсемнәр аша якыннан танышу һәм интервьюга бару. | Июнь | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары |
| 7 | Мамадыш телеведениясенә экскурсия.<br>адио һәм телевидения алып баручысы - Гөлинә Гильмутдинова белән әңгәмә кору. | Июль | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм эти-әниләре |
| 8 | Пешекче һөнәренә төшенү.<br>Балалар белән пешекче турында әңгәмәгә бару. | Август | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм эти-әниләре |
| 9 | 'кытучы һөнәрен шакмактагы рәсемнәр, уеннар аша үзләштерү.<br>Мамадыш шәһәренең 2 нче санлы лицеена әңгәмәгә бару. | Сентябрь-Октябрь | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм эти-әниләре |
| 10 | Сөйлибез һәм күрсәтәбез» проекты эшчәнлегенә нәтиҗә ясау, эти-әниләр һәм балалар белән бердәмлектә музыкаль залда мастер-класс үткәрү. | Ноябрь-Декабрь | Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм эти-әниләре |

**«Сөйләм шакмаклары» ярдәмлеге**

**«Сөйләм шакмаклары»** ярдәмлеге балаларга түбәндәге программа темалары буенча татар сүзен һәм диалогик сөйләмне беркетергә мөмкинлек бирә: урта төркемдә - гаилә, уеннар, бишкә кадәр санау, ашамлыклар; өлкән төркемдә - җиләк-җимеш, яшелчәләр, төсләр, савыт-саба, җиһаз, мәктәпкә әзерлек төркемендә - мәктәп, йорт хайваннары, кыргый җәнлекләр, унга кадәр санау, төсләр. Балаларның белемнәрен ныгыту өчен тәрбияче, яшь төркеменә бәйсез рәвештә, ярдәмлектә тәкъдим ителгән уен биремнәре һәм күнегүләренең барлык вариантларын да куллана ала. Әлеге шакмакларны балаларның уртак эшчәнлегендә дә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә дә кулланылырга мөмкин. Балаларны оештыру формасы индивидуаль яки төркемчә булырга мөмкин.

**«Балачак ТВ» телестудиясе.**

Шакмаклар белән сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст истә кала. Алай гына да түгел, бала диалогик сөйләм һәм, иң катлаулысы, үзлештерелгән тема буенча монологик сөйләмгә дә ирешә. Шул рәвешле җөмлә төзү, сорау алу - җавап бирү, аңлату, ачыклау текстлары өстендә лексиканы ныгытканнан соң, сөйләм интонациясенә игътибар бирелә һәм бала камера каршына микрофон тотып чыгарга әзерлек этабын уза. Диалогик сөйләмдә иң уңышлы нәтиҗә күрсәткән бала “Сөйлибез һәм күрсәтәбез” проекты өчен интервью алырга Мамадыш шәһәре һәм районының атаклы шәхесләре, кул осталары, зур белгечләр янына чыгып китә. Монологик сөйләм күнекмәсе яхшы булган бала шәһәрдәге яңалыкларны яктыртыр өчен вакыйга булган урынга репортаж төшерергә бара. “Һөнәрләр” интервью-тапшыруы зур үсеш алып, күп караулар җыя. Интервьюга әзерләнгәндә бала каршына бер һөнәр иясенең рәсеме куела. Әлеге һөнәр иясе турында беләсе килгәннәрен бала сораулар аша яңгырата. Аның кызыксынуы юнәлешенә бәйле, шакмактагы рәсемнәр ярдәмендә матур, төгәл, җыйнак сорау җөмләләр әзерләнә. Интервью алачак һөнәр иясе белән күзгә күз очрашкач та, бала шакмаклардан аерылмый. Сорауларның эзлеклелеген камера артындагы шамаклар “әйтеп”, исенә төшереп тора. Шулай итеп матур, дөрес, кирәкле әңгәмә барлыкка килә.

**Йомгаклау**

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, балага шакмактагы рәсемнәр ярдәмендә җөмләләрне истә калдыру уңайлырак. Без балаларда булган нәтиҗәне үзебезнең видеолардан күрә алабыз. Тапшырулар Вконтакте социаль челтәрендәге төркеменә урнаштырыла. Тапшыруларны Татарстан гына түгел, бөтен дөньяның татарлары карый һәм җылы кайтавазлар җибәрә. Бу баланың гына телгә кызыксынуын уятмый, эти-әниләргә дә зур этәргеч булып тора. Әти-әниләрдә балаларын татарча сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куярга этәрер өчен, кечкенә журналистларның зур карау җыюларын һәм җылы кайтавазлар уку да җитә. Татар телен яхшы белмәгән бала да, бу күренешне күреп, татарча интервью эшләргә теләк белдерә. “Минем балам да әңгәмә эшләсен әле!” - дигән тәкъдим-үтенечләрне ишетү - татар теле тәрбиячесенең зур максатына ирешүен аңлата. Димәк, ул тапшырулар аша тәрбияләнүчеләрендә генә түгел, әти-әнидә дә кызыксыну-мотивация уята алды.

# ӘДӘБИЯТ


1. Мөбарәкшина З. Якут, чуваш, татар туган тел турында // https://intertat.tatar/news/yakut-cuvas-tatar-tugan-tel-turynda-problema-yas-buynda-gyna-tugel-olkan-buynda-da-5868859. - 10.10.2024
2. “Балачак ТВ” интернет платформасы // https://vk.com/bala4aktvr
3. Журнал «Дошкольная педагогика» №1 (96), январь, 20121 г., ООО «Издательство «ДЕТСТВО-ПРЕСС».
4. Учебное пособие по специальному курсу «ТЕЛЕЖУРНАЛИСТИКА» / Под редаакцией А.В.Толоконниковой, кандидата филологических наук, доцента. – Москва, 2022 – 235 с.
5. Юный журналист. Методическое пособие для педагогов по детской юношеской журналистике / Под редакцией Е.А.Гавриловой. Создано в интелектуальной издательской системе Ridero? 2023/ - 325 с.
6. Есин Б.И. История русской нурналистики / Б.И.Есин – Москва: Флинта. Наука, 2000. – 104 с.
7. Богданов Н.Г. Справочник нурналиста / Н.Г.Богданов, Б.А. Вяземский – Л.:Лениздат, 1971.-685 с.

**Кушымта 1**

**«Мин атам - син әйт!» уены.**

Шакмакларда темалар төрле төсләрдә аерып бирелә. Мәсәлән, кызыл төстәге шакмакларда гаилә, зәңгәрдә - ризык, яшелендә - һөнәрләр һәм башкалар. Бер үк шакмакта, җөмлә төзергә өйрәнү максатыннан, һәр ягында җөмләнең төрле кисәкләре һәм төрле сүз төркемнәрен яктырткан рәсемнәр урын ала. Мисалга, бер кызыл шакмакны кулга алсак, аның бер ягында әни рәсеме булса - ул җөмләнең баш кисәген белдереп киләчәк, алга таба бала әйтәчәк җөмләдә “әни” сүзе ниндидер эшне башкаручы йә ниндидер бер билге, сыйфатка ия, исем сүз төркеме булачак. Шакмакның икенче ягын карасак анда аш сурәтләнгән, башка ягында пешерүне күзалдына китерәчәк плитә рәсеме урын алган һ.б. Әлеге рәсемнәр ярдәмендә геймофикация методының төрле алымнарын тормышка ашырып була. Шулардан иң яратып уйналы торган алым - “Мин атам - син әйт!” уены.Әлеге уен бишәр баладан торган төркемнәрдә уйнала. Баланың һәркайсында бер шакмак була. Беренче бала шакмакны ата һәм анда өскә каз рәсеме чыга.

Бала: *“Бу - каз!”* - дип җавап бирә.

Икенче бала шулай ук шакмакны ата һәм өскә йөгерү пиктограммасы чыга.

Икенче бала: *“Каз йөгерә”*, - дигән җөмләне әйтә.

Өченче балага өй рәсеме чыга.

Ул: *“Каз өйгә кайта”*, - дигән җәенке җөмләне әйтәә.

Шул рәвешле уен дәвам итә. Рәсемнәр ярдәмендә, хикәя җөмлә төзеп, төп мәгълүматны җиткерергә өйрәнгәч, төркемдә булмаган башка бала аларга сораулар биреп, теманы киңәйтеп ачарга, белгән мәгълүматны аңлаешлы телдә җиткерергә омтыла.

**Кушымта 2**

**Тәрбиячеләр белән «Журналистлар булабыз»**
**дигән темага мастер-класс**

Эшчәнлек барышы:

И, туган тел, и матур тел

Әткәм-әнкәмнең теле.....

Тукайлар нигез салган, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле!

Хәерле көн, исәнмесез. Әлеге горур татар телен балаларыбызга өйрәтер, үзебездән эз калдырыр өчен бик күп тырышырга кирәк. Ә без моны җиңел юллар белән, һәрбалага анлаешлы итеп, кызыксындырып башкара алабыз. Мәсәлән, кулымдагы гади, серле шакмак бик зур әһәмияткә ия.

Ә балага шакмактагы рәсемнәр ярдәмендә сүз, сүтезмә, җөмләләрне истә калдыру җайлырак һәм уңайлырак. Чөнки шакмактагы рәсемнәр алар якты (матур, аңлаешлы, төсле, кызыксындыргыч, эчтәлекле)

Ә хәзер хөрмәтле тәрбиячеләр кемнәрдә пресс карта бар, Сезне фокус группага чакырам. Төсләргә карап үзебезнең урынны сайлыйбыз. Без үзебезнең балалар бакчасында татар телендәге “Сөйлибез һәм күрсәтәбез” проектын булдырдык. Сезнең белән дә бүген журналистлар ролен үтәрбез.

“Ел тәрбиячесе - 2024” дигән темага телетапшыру эшләрбез. Безнең тапшыру 4 рубрикадан тора. Димәк, беренче рубрика....... Сезгә рубрикаларга карата текст әзерләргә кирәк.. Сезнең ярдәмчеләр – сөйләм шакмаклары. Әзерләнер өчен ике минут вакыт бирелә.

Ә шул арада хөрмәтле залда утыручылар сезнең белән “Уйлап бел” рубрикасында катнашып алырбыз. Моның өчен камераны ачып, экрандагы куар кодны үзебезгә алабыз, сылтама буенча керәбез һәм безгә биш сорауга бер минут эчендә җавап бирергә кирәк булачак. Башладык.

***1. Телеканалда эшләүче кеше кем дип атала?***

А) резидент

Ә)корреспондент

Б) абонент

***2. Журналистның танылган кеше белән аралашуы – ул.......?:***

А) интервью

Ә) сораштыру

Б) сөйләшү

***3. Интервью нәрсәдән башлана?***

А) кием рәтләүдән

Ә) җыелыштан

Б) елмаюдан һәм сәламләүдән.

***4. Журналистның төп коралы:***

А) текст

Ә) сурәт

Б) тавыш

В) сүз

**5. “Журналистика” термины рус теленә нинди телдән кергән?**

А) инглиз

Ә) алман

Б) француз

В) төрек

Әлеге шакмаклар татар телен үстерүгә безгә бик ярдәм итә. Балаларда үсеш күренә, арта. Әлеге проект белән кызыксынып, “Шаян Тв”да кунака чакырды. Бу проект телне генә үстереп калмый, шулай ук бала иркен аралашырга, тулы җөмлә белән сорау бирергә, җавап ишетергә, зурлар белән аралашырга өйрәнә. Бала камера каршында үзен иркен тотырга өйрәнә. Әлеге табышыбыз уңышлы булды дип горурланып әйтә алабыз.

Сораулар тәмам, катнашуыгыз өчен зур рәхмәт. Җавапларын мастер-класс азагында экранда күрерсез. Фокус группалар сезгә әйләнеп кайтабыз.Журналист ничек чыгыш ясарга тиеш? (елмаеп, матур, дөрес сөйләм белән, ашыкмыйча, интонация белән). Димәк, мин әзер, ә сез әзерме? Тапшыруны мин башлыйм, ә сез чиратлап шакмак белән экран каршына басып чыгыш ясарга тиеш буласыз.

Хәерле көн. Татарстанның мөһим яңалыкларын “Балачак Тв” сөйләр. Экранда мин – Гөлия Сөнгатуллина.

- **“Ел тәрбиячесе – 2024” кайда үткәрелә?**
- **Тәрбичеләр нинди сыйфатка ия булырга тиеш?**
- **Аларга нинди уңышлар теләргә кала, барысы да алдагы минутларда.**
- Тапшыруны “Көн хәбәрләре” рубрикасы дәвам итә.

**2 нче төркем –** “Вакыйга урыныннан репортаж» сүз сезгә.

**3 фокус группа**. Рекламага тукталыйк.

**4 нче ахыргы төркем** журналистлар сездән – “Изге теләкләр” рубрикасын көтеп калабыз.

Әни кебек тәрбияче апа,
Ашыкмыйча гына аңлата
Һәр баланы үз баласы кебек,
Йөрәгеннән чыгып ярата.

Барлык тәрбиячеләргә дә уңышлар теләп,тапшыруны тәмамлыйбыз. Ә тапшыруны дәвам итәбез.

Хөрмәтле, тәрбиячеләр! Сез әлеге тапшыруны тиешенчә дөрес итеп башкарып чыктыгыз, бик зур рәхмәт сезгә. Мастер класстан үзегезгә нәрсә алдыгыз? Безнең алымны, үзегезнең эшегездә кулланыр идегезме?

Дөрес, тулы җавапларыгыз, катнашуыгыз өчен зур рәхмәт.

Ә тулырак безнең видеосюжетларны биредәге куа код аша кереп таныша алсыз. Әйдәгез бергәләп экранан эш нәтиҗәсен карап узыйк.

Милләтнең саклануы турыдан-туры телгә бәйле, чөнки дөньяны танып белү, белем алу һәм аралашу туган тел аша тормышка ашырыла. Тел бетсә, милләт бетә, милләт бетсә халык бетә дигән сүз. Димәк, телебез, милләтебез, дәүләтебез язмышы безнең кулларда, хөрмәтле тәрбиячеләр.

Кушымта 3

Ачык шөгыль **“Галәм киңлекләрендә”**

(мәктәпкә әзерлек төркеме)

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларның галәм турындагы белемнәрен тирәнәйтү.

**Тәрбия бурычы:** балаларда бер-берсе белән килешеп, ярдәмләшеп, команда белән эшләү теләген уяту, уңай психологик халәт тудыру.

**Үстерү бурычы:** балаларның сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын киңәйтү (космос, космонавт, телескоп, планета, галәм, күк җисемнәре, йолдыз, ракета, скафандр һ.б.), сәнгатьле сөйләмне үстерү;

**Белем бирү бурычы:** балаларның йолдызлар, планеталар, космонавтлар, космик техника турындагы белемнәрен системалаштыру; сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү һәм сорауларга төгәл җавап бирә белү.

**Җиһазлар һәм материаллар:** интерактив такта, ракета, ковробук, киемнәр, тюбиклар, телескоп, телефон, скафандр иллюстрациясе, планеталар рәсеме төшерелгән слайдлар, космонавтлар портретлары, йолдызлыклар рәсемнәре.

**Сүзлек өстендә эш**: галәм, чүмеч йолдыз, скафандр, планеталар,йолдызлык.

**Алдан башкарылган эш**: космос, танылган космонавтлар, йолдызлар, кояш, ай һ.б. турында сөйләшү, әңгәмәләр үткәрү; космос турында фотографияләр, журналлар, рәсемнәр карау; космос темасына язылган китаплар уку.

**Эшчәнлек барышы:**

**I Кереш өлеш**

*(Балалар музыка астында керәләр)*

**Тәрбияче**: исәнмесез, дусларым. Мин - Гөлия Раифовна. Сезнең татарча бик яхшы белгәнегезне ишеткәч, “Бәләкәч” балалар бакчасыннан танышырга дип килдем. Үзегез белән дә таныштырып китегез әле. Синең исемең ничек?

**Бала**: Ләйсән.

**Тәрбияче:** шәп, синең күлмәгең күз явын алырлык. Ә син кем буласың?

**Бала:** Алмаз.

**Тәрбияче**: Алмаз – батыр малай, афәрин (танышу дәвам ителә). Мин сезнең белән танышуга чиксез шат (кочаклашалар).

**II Төп өлеш**:

**Тәрбияче:** балалар, минем сезнең кебек бик яхшы татарча белә торган дустым бар, әйдәгез аның белән сезне дә таныштырыйм әле.

**Ак бүре:** сәлам, сәлам дуслар. Минем исемем Ак бүре.

Тәрбияче: ә сезнең Ак бүрене күргәнегез бармы?

**Балалар**: юк.

**Тәрбияче**: балалар, Акбүре сезнең кебек балаларны татарча сөйләшергә өйрәтә. Сез аны һәркөнне телевизордан күрә аласыз. Балалар, сезне бик яхшы татарча белә диләр. Акбүре сезне тикшерер өчен бер табышмак җибәргән. Әлеге табышмакны без шамаклар ярдәмендә әйтеп бирерә тиеш булабыз. Кем җавабын белер икән: (рәсемнәр ярдәмендә укыйлар)

Скафандр кия<br>
Ракетага утыра<br>
Галәмгә оча<br>
Йолдызларны күрә.

**Балалар:** космонавт.

**Тәрбияче:** әлбәттә. Ә сезнең космонавтлар булып карыйсыгыз киләме?

**Балалар:** әйе.

**Тәрбияче:** космоска очучы кеше нинди булырга тиеш?

**Балалар:** акыллы, сабыр, тырыш, батыр, көчле (түгәрәккә алыныбыз).

**Тәрбияче:** без бердәм, көчле, сабыр булганда гына космоска оча алабыз.

**Ак бүре:** шәп, шундый күп беләсез. Сезнең белән космоска да очарга була.

**Тәрбияче:** дусларым, космоска очар өчен безгә файдалы ризыклар кирәк була. Әйдәгез әле мин сезне ризыклар сайларга чакырам. Балалар, космоска бары тик шушындый савытларда гына ризык алып барырга ярый. Кем нәрсә сайлый?

**Балалар:** сөт.

**Тәрбияче**: сөтне безгә нәрсә бирә?

**Бала:** сыер.

**Тәрбияче:** әлбәттә. Алмаз, ә син нинди ризык сайладың?

**Бала:** ботка.

**Тәрбияче:** нинди боткалар беләсең, Алмаз? Балалар бакчасында нинди төрләрен бирәләр?

**Балалар:** дөге боткасы, манный боткасы (берничә баладан ризык турында сорау алу, һәрберсерсе ала тора, ябыштыра)

**Тәрбияче:** дусларым, ә нигә берегез дә кола белән чипсыны сайламады?

**Балалар:** чөнки ул зыянлы.

**Тәрбияче:** бик дөрес. Без файдалы ризыклар ашасак кына көчле, матур, батыр була алабыз. Әйдәгез ризыкларны тиешле урынга урнаштырып куйыйк әле. Балалар, галәмгә очар өчен безнең барысы да614 бармы?

**Балалар:** юк

**Тәрбияче:** юк шул. Ә галәмгә-космоска нәрсәдә очалар?

**Балалар**: ракетада.

**Тәрбияче:** ә без ракетаны каян ала алабыз соң?

**Балалар:** кибеттән, Казаннан.

**Тәрбияче:** ә мин сезгә галәм станциясенә шалтыратырга тәгъдим итәм. Ә ракетаны ничек сорыйсы була, әйдәгез минем янга утырыгыз әле. Иң беренче шалтыраткач нишләргә кирәк балалар.

**Балалар:** исәнләшергә.

**Тәрбияче:** ә ничек исәнләшеп була?

**Балалар:** исәнмесез.

**Тәрбияче:** дөрес, ягымлы итеп исәнләшергә кирәк. Ә ракетаны ничек сорыйбыз?

**Балалар:** безгә ракета кирәк иде дип.

**Тәрбияче**: әлбәтә.Ә телефоннан сөйләшеп бетергәндә ни дип әйтергә кирәк?

**Балалар:** саубулыгыз.

**Тәрбияче**: тагын нинди ягымлы сүз әйтергә була?

**Бала:** рәхмәт.

**Тәрбияче:** кемнең шалтыратасы килә. (санамыш 1 йолдыз, 2 йолдыз, сары йолдыз. Баланы сайладык)

**Бала:** Исәнмесез

**Галәм станциясе:** Исәнмесез, бу галәм станциясе, сезгә нәрсә кирәк?

**Бала:** безгә ракета кирәк

**Галәм станциясе:** Сез кайсы балалар бакчасыннан?

**Балалар:** Теремок

**Галәм:** яхшы, сезгә тиздән ракета килеп җитәр. Саубулыгыз

**Балалар:** рәхмәт, саубулыгыз.

**Тәрбияче:** минем сезгә бер тәгъдимем бар: космоста булган хәлләрне видеога төшереп сюжет ясау һәм кайткач әниләрегезгә күрсәтерсез.Сез ризамы?

**Тәрбияче**: ә хәзер бирегә килегез әле. Болар кемнәр?

**Балалар:** кыз белән малай.

**Тәрбияче**: дөрес, аларның да космоска очсылары килә, алар әзерме?

**Балалар:** аларның киемнәре юк.

**Тәрбияче:** балалар, космоска нинди киемсез утырыга ярамый?

**Балалар**: җаваплар (скафандр һәм шлем)

**Тәрбияче:** әлбәттә. Балалар, карагыз әле. Кызлар кызны, ә малайлар малайны киендерергә тиеш була. Бирედән һәрберегез берәр кирәкле булган киемне сайлап алып кызлар кызны, ә малайлар малайны киендерергә тиеш була. (ковробук, киендерәләр)

**Тәрбияче:** безнең кыз белән малай да та космоска очарга әзер.

Балалар, карагыз әле, бу ни икән? (ракетаны күзәтәләр).Нәни дусларым,барыгыз да минем янәшәмә килегез әле. (әкрен генә япманы тотабыз)

1,2,3

Зәңгәр ятмәне ач.

**Тәрбияче:** ракетага утырыр өчен пароль әйтергә кирәк була. Парольдә сез нинди икәнегезне әйтергә тиеш буласыз. (батыр малай, матур кыз) Әйдәгез бергәләшеп ракетага утырышыйк:

Космос эчендә саныйбыз. 1, 2, 3, 4, 5, 6,7, 8, 9,10.

(ракета тавышы, күтәрелү)

**Тәрбияче**: карагыз әле балалар планета ничек матур. Балалар, нәрсә бу?

**Бала:** кояш.

**Тәрбияче:** кояш ни өчен кирәк?

**Бала:** җылытыр өчен, көнне яктыртыр өчен.

**Тәрбияче**: бик дөрес. Ә бу ни?

**Бала:** ай.

**Тәрбияче:** ай көннең кайсы тәүлегендә чыга?

**Бала:** кич җиткәч.

**Тәрбияче:** ә болар ни?

**Балалар**: йолдызлар.

**Тәрбияче**: йолдызлар нинди төстә?

**Балалар:** сары.

**Тәрбияче:** балалар, безнең исем булган күк йолдызларның да исемнәре бар. Мәсәлән бу йолдызга нинди исем бирер идегез?

**Бала**: чүмеч йолдыз. Чөнки, ул йолдызга ошаган.

**Тәрбияче:** сез нинди планета исемнәрен беләсез?

**Балалар**: меркурий, сатурн,юпитер, венера. Ә без нинди планетада яшибез?

**Бала:** җир.

**Тәрбиче:** бик дөрес. Ә хәзер ял итеп алыйк.

(кояш, ай)

1,2,3,4

1,2,3,4

Әйдәгез әле бергәләшеп телескоп ярдәмендә җир шарын күзәтик. Алсу, син нәрсә күрәсең?

**Алсу:** йолдыз.

**Тәрбияче:** Ә сез галәмгә иң беренче кем очканын беләсезме?

**Балалар:** Ю.А.Гагарин.

**Тәрбияче**: бик дөрес. Иң элек космос-галәмгә Белка һәм Стрелка исемле этләрне очырталар. Алар исән-сау кайткannан соң, иң беренче булып кешеләрдән Юрий Гагарин оча. Шул көннән башлап 12 апрель космонавтика көне булып билгеләнә.

**Тәрбияче:** дусларым, галәмнән үзебезнең ясаган рәсемнәрне истәлеккә алып кайтырга тәгъдим итәм. Сез ризамы?

**Балалар:** риза.

**Тәрбияче:** моның өчен безгә әлеге таякчыклар ярдәмгә килер. Шушы таякчыклар белән трафрет ярдәмендә рәсемнәрегезне төшерә аласыз. (һәрбер баладан ни ясаган сораштыру, балалар белән рәсем ясау).

**Тәрбияче:** ә хәзер кайткач әниләрегезгә күрсәтү өчен камерага нәрсәгә ясаганыгызны камерага карап (мин сары кояш ясадым). Әфәрин, балалар, булдырдыгыз.

Дусларым, хәзер безгә балалар бакчасына кайтыр вакыт җитте. Үз урыннарыгызга басыгыз. (пароль матур кыз, батыр малай; саннарны кирегә саныйбыз)

**III Йомгаклау өлеше:**

**Акбүре:** дусларым, сезгә бүгенге сәяхәт ошадымы? (әйе)

**Тәрбияче**: галәмдә нәрсәләр күрдегез, Акбүрегә сөйләгез әле (балалар сөйли).

**Тәрбияче:** берәр яңалык белән таныштыгызмы? (балалардан җавап)

Ак бүренең дә татарча яхшы белә торган торган “Салаватиклар” исемле дуслары бар. Әйдәгез алар белән бергә Ак бүрегз планеталарны санап күрсәтәбез. (шакмаклар ярдәмендә күк җисемнәрен атыйбыз)

**Акбүре:** рәхмәт, дусларым. Татар телен яхшы белгәнегез өчен миннән сезгә бүләк (сихри тавыш)

**Тәрбияче:** Әлеге куар код ярдәмендә көн дә әниләрегез белән Акбүрене карарга онытмагыз. Ул сезне татар телендә күбрәк аралышырга өйрәтер. Гади генә куар кодлар түгел, ә сезнең фтосурәтләр белән. Тәрбияче: балалар, бүген сезнен белән миңа бик күңелле булды. Татар телендә бик яхшы аралашасыз икән. Кызганыч, миңа китергә вакыт. Ә хәзер әйдәгез мин сезне төркемегезгә озатам. (җырлап чыгып китәләр).

**Кушымта 4**

**Ата-аналар өчен анкета**

**1. Ф.И.О. (исемегез, фамилиягез, әтиегезнең исеме):**

---

**2. Яшегез:**

---

**3. Белемдәрәҗәсе:**

- Уртамәктәп (классы) ______
- Колледж/техникум
- Югарыукуйорты (факультет/башкаручы программа) ______
- Башка ______

**4. Татар теле белән эшчәнлегегез:**

- Ана теле булараксөйләшәм
- Өйрәнүчебуларакөйрәнәм
- Көндәлектормыштасирәккулланам, әммакызыксынам
- Башка (аңлатма бирәсез): ___________________________

**5. Татар теле дәресләребуенчаүзбелемегезненичек бәялисез?**

- Югары
- Уртача
- Түбән

**6. Журналистикагакызыксынудәрәҗәсе:**

- БИК кызыксынам, журналист булыргателим
- Журналистика турындакызыклымәгълүматларукыйм/карыйм
- Сирәккызыксынам, ләкиняңанәрсәләр өйрәнергә телим
- Проекткакатнашубеләнгенәкызыксынам

**7. Медиа өлкәсендәэштәҗрибәсегез бармы? (блог, мәкаләләр, видео, радио һ.б.)**

- Бар (аңлатып бирәсез): ___________________________________
- Юк

**8. Проекттакатнашыргателәгәнөлкәләр:**

- Мәкаләязу (текстларөстендәэшләү)
- Видео сюжетлартөзүһәммонтажлау
- Социальшебкәләрдәэшләү (контент төзү)
- Татар теле кулланып медиа эшләре төзү
- Башка идеяләр: ________________________________________

**9. Татар теле һәм журналистика өлкәсендәниндитемаларныөйрәнергәкызыксынасыз? (3–5 мисалкитерегез)**

1. ______________________________
2. ______________________________
3. ______________________________

**13. Проект турынданичек белдегез?**

- Дусларданишеттем
- Соц.шебкәләрдәнкарадым
- Балалар бакчасыннанхәбәралдым
- Башка: ______________________________

**14. Проект оештырубуенчакиңәшләрһәмфикерләр (ихтиярлырәвештә):**

______________________________

______________________________

**15. Элемтә мәгълүматлары:**

- Телефон номера: ______________________________
- Электрон почта (E-mail): ______________________________
- Telegram/WhatsApp номера: ______________________________

---

**Рәхмәт!**Анкетанытутырып, [электрон почта адреса] яки [башка юл] ашаҗибәргез.

**Кушымта 5**






**Шакмактагы рәсемнәр ярдәмендә сүз, сүзтезмә өйрәнәбез.**






Район башлыгы – Анатолий Иванов белән очрашу

Кытай татары – Кодрәт Камал белән әңгәмә

**“Бала сити” да кунакта**




ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов белән әңгәмә. “Бала сити” да үткән “Туган тел фестивале” дип исемләнгән чарада үзебезнең “Сөйлибез һәм күрсәтәбез” проектын презентацияләдек. Кечкенә журналистыбыз саф татар телендә биргән сорауларга каршы Марат Әхмәтов “Искиткеч. Афәрин” , дип елмаеп җавап бирде. Әлеге чарада мин мастер-класс үткәрдем һәм инде минем “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телен үстерүдә шакмаклар ярдәмендә телевизион журналистика алымнары” дигәнмәкаләм “Бала сити” чыгарган методик китапчыкта үз урынын алды.







**«БАЛАЧАК ТВ" ШАЯНда**




Ин беренчеләрдән булып безнең проектны вконтакте челтәрендә "Шаян ТВ"лар күреп алды. Дустым Язилә белән Казан шәһәренә җылы әңгәмә бардык. Кызыклы, уйландыргыч сорауларына җаваларыбызны ишеттереп кайттык. Балалар өчен кызыклы, кирәкле тапшырулар нәкъ – Шаян Твдан күреп була. Шаян ТВлардан үрнәк алып эшлибез дисәм да ялгыш булмас.





ТНВ

ШАЯН

РӘХМӘТ ХАТЫ

Сөнгатуллина Гөлия Раиф кызына!

Казань – 2022

Рәхмәт хаты. Татар халкының телен, мәдәниятен үстерүдә зур өлеш керткән өчен.